| ГЛАВА<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.11. 2019 с.Старое Дрожжаное № 50

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районында гражданнар оборонасын оештыру
һәм алып бару турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 30 сентябрендәге 1274 номерлы РФ Хөкүмәте карарына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының 2016 елның 20 гыйнварындагы 2 номерлы карары (31.05.2009 ел, № 27 редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**15.4 пунктының алтынчы абзацында** «, тирәнәйтелгән биналарда һәм җир асты киңлегенең башка корылмаларында» сүзләрен өстәргә;

**15.9 пунктының икенче абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе территориясендә радиацион, химик, биологик хәлне күзәтү һәм тикшереп тору функцияләрен гамәлгә ашыручы гамәлдәге махсус учреждениеләр, бүлекчәләр һәм хезмәтләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм оешмаларның гражданнар оборонасын күзәтү һәм лаборатор контрольдә тоту челтәрен булдыру һәм әзерлеген тәэмин итү;»;

**15.15 пунктның дүртенче абзацында** «планнарны эшләү һәм төзәтү» сүзләрен «планлаштыру»сүзенә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гражданнар оборонасын алып бару һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2011 елның 14 июнендәге 25 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Чүпрәле муниципаль район
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Е. Ярухин